МИНИСТЕРСТВО КУЛЬТУРЫ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул. Пушкина, д. 66/33, г. Казань, 420015

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӘДӘНИЯТ МИНИСТРЛЫГЫ
Пушкин ур., 66/33нче йорт, Казан ш., 420015

Тел.: (843) 264-74-01, факс: (843) 292-07-26. mkrt@tatar.ru, mincult.tatarstan.ru

**ПРИКАЗ** г.Казань **БОЕРЫК**

**14.03.2017** **№ 222 од**

Казан шәһәре, Зур Кызыл урамы, 10 нчы йорт адресы буенча урнашкан “Торак йорт, 1840 ел” төбәк әһәмиятенә ия мәдәни мирас объекты территориясе чикләрен раслау турында

“Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни ядкәрләр) турында”гы 2002 елның 25 июнендә кабул ителгән 73-ФЗ номерлы законына, “Татарстан Республикасында мәдәни мирас объектлары турында”гы 2005 елның 1 апрелендә кабул ителгән 60-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законына, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан 2015 елның 19 мартында кабул ителгән 171 нче “Казан шәһәре, Зур Кызыл урамы, 10 нчы йорт адресы буенча урнашкан “Торак йорт, 1840 ел” юкка чыккан төбәк әһәмиятенә ия мәдәни мирас объектын торгызу турында”гы карарына нигезләнеп, махсус җайга салына торган шәһәр төзелеше эшчәнлеге объектлары буларак, төбәк әһәмиятенә ия мәдәни мирас объектларын һәм аларның территорияләрен саклауны һәм дәүләт тарафыннан саклап тотуны тәэмин итү максатларында,

**БОЕРАМ:**

1. Казан шәһәре, Зур Кызыл урамы, 10 нчы йорт адресы буенча урнашкан “Торак йорт, 1840 ел” төбәк әһәмиятенә ия мәдәни мирас объекты территориясе чикләрен расларга (1 нче кушымта).
2. Казан шәһәре, Зур Кызыл урамы, 10 нчы йорт адресы буенча урнашкан “Торак йорт, 1840 ел” төбәк әһәмиятенә ия мәдәни мирас объекты территориясеннән файдалану режимын расларга (2 нче кушымта).
3. Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы тарафыннан 2015 елның 3 октябрендә расланган “Казан шәһәре, Зур Кызыл урамы, 10 нчы йорт

адресы буенча урнашкан “Торак йорт, 1840 ел” төбәк әһәмиятенә ия мәдәни мирас объекты территориясе чикләрен раслау турында”гы боерыгын үз көчен югалткан дип танырга.


4. 4. Боерыкның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Министр А.М. Сибагатуллин

______ел_____боерыкка
1 нче кушымта

Казан шәһәре, Зур Кызыл урамы, 10 нчы йорт адресы буенча урнашкан
“Торак йорт, 1840 ел” төбәк әһәмиятенә ия мәдәни мирас объекты
территориясе ЧИКЛӘРЕ

Казан шәһәре, Зур Кызыл урамы, 10 нчы йорт адресы буенча урнашкан
“Торак йорт, 1840 ел” төбәк әһәмиятенә ия мәдәни мирас объекты
территориясе чикләренең картасы (схемасы)



Казан шәһәре, Зур Кызыл урамы, 10 нчы йорт адресы буенча урнашкан “Торак йорт, 1840 ел” төбәк әһәмиятенә ия мәдәни мирас объекты территориясе чикләренең **картографик тасвирламасы**

Казан шәһәре, Зур Кызыл урамы, 10 нчы йорт адресы буенча урнашкан “Торак йорт, 1840 ел” төбәк әһәмиятенә ия мәдәни мирас объекты территориясе чикләре түбәндәгечә үтә:

**Төньяк-көнчыгыш өлеш:** Зур Кызыл урамы буенча, җир кишәрлегенең ян чигеннән, кызыл линия буйлап, җир кишәрлегенең алгы чигеннән, җир кишәрлегенең ян чигенә кадәр (б.н. № 1-2).
**Көньяк-көнчыгыш өлеш:** Зур Кызыл урамыннан, җир кишәрлегенең ян чиге буенча, җир кишәрлегенең эчке квартал чигенә кадәр (б.н. 2-3).
**Көньяк-көнбатыш өлеш:** җир кишәрлегенең ян чигеннән, җир кишәрлегенең эчке квартал чиге буенча, җир кишәрегенең ян чигенә кадәр (б.н. 3-4-5-6-7).
**Төньяк-көнбатыш өлеш:** җир кишәрлегенең эчке квартал чигеннән җир кишәрлегенең ян чиге буенча Зур Кызыл урамына кадәр (б.н. 7-1).

Казан шәһәре, Зур Кызыл урамы, 10 нчы йорт адресы буенча урнашкан “Торак йорт, 1840 ел” төбәк әһәмиятенә ия мәдәни мирас объекты территориясе чикләренең **борылыш нокталары таблицасы**

| Нокталар № | МСК 16 системасында нокталарның координаталары | | 1984 елгы бөтендөнья геодезик координаталар системасында (WGS 84) нокталарның координаталары | |
|---|---|---|---|---|
| | X | Y | Төньяк киңлек B | Көнчыгыш озынлык L |
| 1 | 476813.47 | 1304995.15 | 55°47' 55.06" | 49°06' 40.81" |
| 2 | 476803.00 | 1305037.03 | 55°47' 54.72" | 49°06' 43.21" |
| 3 | 476765.02 | 1305027.08 | 55°47' 53.49" | 49°06' 42.64" |
| 4 | 476766.91 | 1305017.41 | 55° 47' 53.55" | 49°06' 42.08" |
| 5 | 476775.53 | 1305019.12 | 55°47'53.83" | 49°06' 42.18" |
| 6 | 476786.25 | 1305012.70 | 55°47' 54.18" | 49°06' 41.81" |
| 7 | 476793.05 | 1304989.58 | 55°47' 54.40" | 49°06' 40.49" |
| 1 | 476813.47 | 1304995.15 | 55°47' 55.06" | 49°06' 40.81" |

_____ел_____боерыкка
2 нче кушымта

Казан шәһәре, Зур Кызыл урамы, 10 нчы йорт адресы буенча урнашкан “Торак йорт, 1840 ел” төбәк әһәмиятенә ия мәдәни мирас объекты территориясе чикләреннән **файдалану режимы**

Төбәк әһәмиятенә ия мәдәни мирас объекты территориясе чикләрендә түбәндәгеләр рөхсәт ителә:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан 2015 елның 19 мартында кабул ителгән 171 нче “Казан шәһәре, Зур Кызыл урамы, 10 нчы йорт адресы буенча урнашкан “Торак йорт, 1840 ел” юкка чыккан төбәк әһәмиятенә ия мәдәни мирас объектын торгызу турында”гы карары нигезендә, юкка чыккан мәдәни мирас объектын, Зур Кызыл урамы линиясе буенча ишегалды хезмәтләрен һәм флигельне торгызу;

яңадан торгызу өчен кирәкле җитәрлек күләмдә фәнни мәгълүматлар булганда мемориаль һәм архитектур-ансамбль ягыннан кыйммәтле саналган юкка чыккан тарихи элементларны торгызу;

мәдәни мирас объектын сак предметын тәшкил итүче үзенчәлекләрен үзгәртмичә рөхсәт ителгән функциональ файдалану төрләре нигезендә заманча куллану өчен яраклаштыру;

булган инженер инфраструктурасы объектларын капиталь ремонтлау (тышкы су белән тәэмин итү челтәре, канализацияләр, җылылык, газ, электр белән тәэмин итү, телефонлаштыру);

төзекләндерү: мәйданчыкларга, якын килү һәм транспорт уза торган урыннарына традицион материаллар (таш, гранит һәм табигый материалга охшаш башка материаллар) түшәү; тарихи мохит элементлары характеристикаларына җавап бирә торган аерым урнаштырылган яктырту җайланмаларыннан файдалану;

яшелләндерү: агачларның кыйммәтле төрләрен саклап калу;

мәдәни мирас объектлары фасадларында мәйданы 0,4 квадрат метрдан артмаган мәгълүмати язулар һәм билгеләмәләрне мәдәни мирас объектының беренче катыннан да югары күтәрмичә урнаштыру;

Россия Федерациясенең 1992 елның 7 февралендә кабул ителгән № 2300-1 “Кулланучылар хокукларын яклау турында”гы Законы нигезендә, кулланучыга әзерләүченең (башкаручы, сатучы) атамасы турындагы мәгълүматны җиткерү өчен бинаның, корылманың беренче катында мәйданы 0,3 квадрат метрдан артмаган вывеска һәм реклама конструкцияләре урнаштыру;

тарихи-архитектур тикшеренүләр нигезендә махсус эшләнгән проектлар буенча киосклар, өслекләр, кече архитектур формалар урнаштыру;

түбәндә рөхсәт ителгән файдалану төрләре нигезендә булган капиталь төзелеш объектлары исемлеге тәкъдим ителә, шулай ук җир кишәрлекләреннән

файдалану (капиталь төзелеш объектлары төземичә һәм капиталь булмаган корылмалар урнаштырмыйча):

- эшмәкәрлек (код 4.0);
- эшлекле идарә (код 4.1);
- кибетләр (код 4.4);
- банклар һәм иминиятләштерү эшчәнлеге (код 4.5);
- җәмәгать туклануы (4.6);
- кунакханә хезмәте күрсәтү (4.7);
- күңел ачу (4.8);
- капиталь төзелеш объектларын иҗтимагый файдалану (3.0);
- социаль хезмәт күрсәтү (3.2);
- капиталь төзелеш объектларына көнкүреш хезмәте күрсәтү (3.3);
- сәламәтлек саклау (код 3.4);
- белем бирү һәм мәгариф (код 3.5);
- мәдәни үсеш (код 3.6);
- дини максатларда файдалану (код 3.7);
- иҗтимагый идарә (код 3.8);
- фәнни эшчәнлекне тәэмин итү (код 3.9);
- ветеринария хезмәте күрсәтү (код 3.1);
- торак корылмалар (код 2.0);
- шәхси торак төзелеше өчен (код 2.1);
- аз катлы күпфатирлы торак төзелеше (код 2.1.1);
- блоклы торак төзелеше (код 2.3);
- урта катлы торак төзелеше (код 2.5);
- торак корылмаларга хезмәт күрсәтү (код 2.7);
- җиңел сәнәгать (код 6.3);
- азык-төлек сәнәгате (код 6.3);
- спорт (код 5.1);
- тарихи-мәдәни эшчәнлек (код 9.3);
- парклар, скверлар, мәйданнар, бульварлар, яр буе урыннарын урнаштыру (код 12.0).

Алда аталган эшләр Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы тарафыннан килештерелгән мәдәни мирас объектларын саклап калу буенча проект документларын әзерләү һәм эшләр башкару буенча йөкләмәләр, күрсәтелгән эшләрнең башкарылуын Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы контрольдә тоткан очракта – проект документлары, Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы тарафыннан мәдәни мирас объектын саклау эшләре алып бару өчен язмача рөхсәт кәгазе нигезендә башкарыла.

Җирле (муниципаль) әһәмияткә ия мәдәни мирас объектлары территориясе чикләрендә түбәндәге эшләр **тыела**:

капиталь төзелеш объектлары һәм аларның өлешләрен урнаштыру, шулай ук проектлау, җир казу, төзелеш, хуҗалык һәм мәдәни мирас объектларын саклау белән бәйле булмаган башка эшләр башкару;

мәдәни мирас объектлары фасадында һәм түбәсендә кондиционерлар, зур габаритлы антенналар һәм башка инженер җиһаз элементлары урнаштыру;

инженер инфраструктурасы объектларын (суүткәргечнең тышкы челтәре, канализация, җылылык, электр белән тәэмин итү, телефонлаштыру) җир өстеннән үткәрү;

ачык һәм ябык машина кую урыннарын көйләү; санитар кисүләрдән тыш агачларның кыйммәтле төрләрен кисү.